КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

2026 ел, 5 май | г.Казань | № 665

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түләүсез юридик ярдәм күрсәтү дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибен раслау турында» 2013 ел, 21 октябрь, 774 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 20 февраль, 103 нче; 2015 ел, 11 март, 144 нче; 2016 ел, 24 март, 164 нче; 2016 ел, 15 август, 563 нче; 2017 ел, 21 февраль, 111 нче; 2017 ел, 7 декабрь, 951 нче; 2019 ел, 20 сентябрь, 858 нче; 2023 ел, 11 март, 239 нчы; 2023 ел, 5 октябрь, 1237 нче; 2024 ел, 10 февраль, 75 нче; 2024 ел, 19 апрель, 264 нче; 2025 ел, 29 май, 374 нче; 2025 ел, 14 ноябрь, 949 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Түләүсез юридик ярдәм күрсәтүнең дәүләт системасы кысаларында гражданнарга түләүсез юридик ярдәм күрсәтүче адвокатлар хезмәте өчен түләү һәм адвокатларның түләүсез юридик ярдәм күрсәтү чыгымнарын компенсацияләү тәртибенә, әлеге

Тәртипнең 4 нче кушымтасындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле «с» пунктчасын өстәп, үзгәреш кертергә:

«с) аларны мәҗбүри күченүчеләр, качаклар дип тану турында үтенечнамә белән мөрәҗәгать итүче, мәҗбүри күченүчеләр, качаклар дип танылган яисә Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны алган затлар, әгәр алар социаль ярдәм чараларын күрсәтүгә, аларны мәҗбүри күченүчеләр, качаклар дип тануга, Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирүгә яисә Россия Федерациясе гражданлыгына кабул итүгә бәйле мәсьәләләр буенча түләүсез юридик ярдәм күрсәтүне сорап мөрәҗәгать итсә:

эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органы тарафыннан бирелгән затны мәҗбүри күченүче дип тану турындагы үтенечнамәне теркәү турында таныклык күчермәсе яки Россия Федерациясе территориясендә качак дип тану турындагы үтенечнамәне карап тикшерү турындагы таныклык күчермәсе;

эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органы тарафыннан бирелгән мәҗбүри күченүче таныклыгы күчермәсе яки качак таныклыгы күчермәсе;

эчке эшләр өлкәсендә федераль башкарма хакимият органының территориаль органы тарафыннан бирелгән Россия Федерациясе территориясендә вакытлыча сыену урыны бирү турында таныклык күчермәсе.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин